| СОВЕТ ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ |
|---|---|---|
| **РЕШЕНИЕ**<br>**09.09.2016** | Зеленодольск шәһәре | **КАРАР**<br>**№ 124** |

2016-2021 елларга һәм 2030 елга кадәр план чорына Зеленодольск муниципаль районының социаль-икътисадый үсеш стратегиясен раслау турында

2003 елның 6 ноябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә һәм гавами тыңлаулар нәтиҗәләрен карап чыкканнан соң, Зеленодольск муниципаль районы Советы **карар кылды**:

1. 2016-2021 елларга һәм 2030 елга кадәр план чорына Зеленодольск муниципаль районының Социаль-икътисадый үсеш стратегиясен (алга таба - ЗМР стратегиясе) расларга (кушымта итеп бирелә).
2. Зеленодольск муниципаль районы составына керүче җирлек башлыкларына ЗМР Стратегиясе белән интеграцияләнгән территориянең социаль-икътисадый үсеше буенча чаралар планын эшләргә һәм расларга тәкъдим итәргә.
3. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетына:
3.1. ЗМР Стратегиясен гамәлгә ашыру мониторингын оештырырга;
3.2. Зеленодольск муниципаль районы Советына ЗМР стратегиясендә чагылыш тапкан максатларны һәм бурычларны гамәлгә ашыру өчен кирәкле булган Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты структурасы проектын тәкъдим итәргә.
4. Әлеге карарны Интернет челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырырга.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зеленодольск муниципаль районы Советының социаль-икътисадый үсеше, бюджет-финанс мәсьәләләре, муниципаль милек һәм эшкуарлыкны үстерү буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

**Зеленодольск муниципаль районы Башлыгы,**
**Советы рәисе** **А. В. Тыгин**